| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ
«16» апреля 2024 года

Норлат ав.

КАРАР
№156

Норлат авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендәге 119 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 130 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 172 номерлы, 2020 елның 12 августындагы 231 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 41 номерлы, 2022 елның 20 декабрендәге 92 номерлы, 2023 елның 20 гыйнварендәге 100 номерлы, 2023 елның 7 февралендәге 104 номерлы, 2023 елның 19 апрелендәге 110 номерлы, 2023 елның 05 июлендәге 122 номерлы, 2023 елның 04 сентябендәге 128 номерлы, карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Норлат авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 ноябрендәге 119 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Норлат авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 130 номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 172 номерлы, 2020 елның 12 августындагы 231 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 41 номерлы, 2022 елның 20 декабрендәге 92 номерлы, 2023 елның 20 гыйнварендәге 100 номерлы, 2023 елның 7 февралендәге 104 номерлы, 2023 елның 19 апрелендәге 110 номерлы, 2023 елның 05 июлендәге 122 номерлы, 2023 елның 04 сентябендәге 128 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә: (алга таба-Нигезләмә)

1.1. 2.3 пунктында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.2. 4.2 пунктында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.3. 5.1 пунктында «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.4. 9.2 пунктында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.5. 10.1. пунктының 5 нче пунктчасында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.6. 10.3. пунктының 4 нче пунктчасында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.7. 10.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пунктча тулыландырырга:

«12) әлеге положениенең 15.1 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) яллаучы вәкиле (эш бирүче)карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, язма рәвештә хәбәр итәргә, (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»

1.8. 11.1 пунктның 8 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

1.9. 11.3.пунктның 1 нче пунктчасында в пунктчасындагы ,« Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.10. 11.3. пунктының 3 нче пунктчасында ,« Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе аппаратында» - сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.11. 11.3. пунктның 5 нче пунктчасында ,« Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе аппаратында» һәм «,башка муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре тарафыннан» - сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.12. 11.3. пунктының 8 нче пунктчасында «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы "Норлат авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.13. 11.7. пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» һәм «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.14 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 15.1 нче пунктчасы белән тулыландырырга:

«15.1. Анкетаны тәкъдим итү, анкетадагы мәгълүматның үзгәрүе турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү.

15.1.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә гражданин анкета тәкъдим итә.

15.1.2. Муниципаль хезмәткәр яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

15.1.3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

15.1.4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган җәмәгать хакимияте органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

1.15. 16.4. пунктнын 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) әлеге Нигезләмәнең 15.1 маддәсендә каралган анкета;»;

1.16. 16.5. нчы пункта «Мәгълүмат» сүзләреннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.17. 24.2 пунктында «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе» һәм ,« Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.18. 30 статьясының статьяның 1 өлеше 11 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.19. 30 нчы статьяның 1 нче элешен түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«11.1.) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү;»;

1.20. 33.2. пунктында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

1.21. 33.3. пунктында «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» һәм «, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сайлау комиссиясе» сүзләрен - тешереп калдырырга;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм шулай ук түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин ур., 17 йорт («Идел Аръягы» ҮКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы,

Норлат авылы, Гагарин ур., 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

Норлат авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе И.М.Саттаров